ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), аңа «башка федераль дәүләт органнары,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Үзәк банкы (Россия Банкы),» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. «Хезмәт ветераны» исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы нигезләмәләрнең гамәлдә булуы (әлеге Закон редакциясендә) шулай ук әлеге Закон үз көченә кергән көннән соң «Хезмәт ветераны» исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгасы белән әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр бүләкләнгән затларга кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 10 октябрь
№ 68-ТРЗ